| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 октябрь 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Вәлиев авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Вәлиев авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 15 ноябренә 13 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Вәлиев авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

-авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Яңа Чыршылы поселогы, Заречная, 25, Центральная 12А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә.Мөхәмәтшина